ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Казан шәһәрендәге районнар чикләрен үзгәртү турында һәм «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 497-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

«Казан шәһәрендәге районнар чикләрен үзгәртү турында һәм «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 497-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2281-VI ДС

II укылышка
әзерләнгән проект

**Казан шәһәрендәге районнар чикләрен үзгәртү турында**
**һәм «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Әлеге законның кушымтасы нигезендә Казан шәһәре районнарының чикләрен үзгәртергә.

**2 статья**


2015 елның 25 апрелендәге 30-ТРЗ номерлы «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 4; 2016, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Казан шәһәрендәге
районнар чикләре турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

Казан шәһәрендәге районнар
чикләренең

**Карта-схемасы**



2) 2 нче кушымтада:

а) «Казан шәһәренең Вахитов районы чиген картографик тасвирлау» бүлегенең дүртенче абзацында «Нурсолтан Назарбаев урамының җөп ягы буйлап Габдулла Тукай урамына кадәр, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап Сара Садыйкова урамына кадәр» сүзләрен «Нурсолтан Назарбаев урамының так ягы буйлап Вахитов мәйданына кадәр, Вахитов мәйданының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап көньяк-көнбатышка таба һәм көньяк ягы буйлап көнбатышка таба бара, Техника һәм Габдулла Тукай урамнарын кисеп үтеп, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап Сары Садыйкова урамына кадәр төньякка таба уза» сүзләренә алмаштырырга;

б) «Казан шәһәренең Идел буе районы чиген картографик тасвирлау» бүлегенең беренче абзацында «Нурсолтан Назарбаев урамының җөп ягы буйлап Габдулла Тукай урамына кадәр, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап Сары Садыйкова урамына кадәр» сүзләрен «Нурсолтан Назарбаев урамының так ягы буйлап Вахитов мәйданына кадәр, Вахитов мәйданының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап көньяк-көнбатышка таба һәм көньяк ягы буйлап көнбатышка таба бара, Техника һәм Габдулла Тукай урамнарын кисеп үтеп, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап Сары Садыйкова урамына кадәр төньякка таба уза» сүзләренә алмаштырырга;

в) «Казан шәһәре Совет районы чикләренең картография тасвирламасы» бүлегенә түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:
«Совет районының басу аша кишәрлеге («Фәнни шәһәрчек») чиге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы белән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге басу аша кишәрлеге («Фәнни шәһәрчек») чиге буенча уза.».


**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе




«Казан шәһәрендәге районнар
чикләрен үзгәртү турында һәм
«Казан шәһәрендәге районнар чикләре
турында» Татарстан Республикасы
Законына үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

Казан шәһәрендәге районнарның
үзгәрешләр исәпкә алынган чикләре
карта-схемасы



**Беренче укылышта кабул ителгән «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 497-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектына Комитет тарафыннан хупланган төзәтмәләр таблицасы**

| № т/б | Татарстан Республикасы Законының гамәлдәге редакциясендәге статьялары тексты | Беренче укылышта кабул ителгән закон проектының аерым статьялары тексты | Төзәтмә авторы һәм аның эчтәлеге | Закон проекты текстының Комитет тарафыннан хуплан-ган төзәтмәләрне исәпкә алган яңа редакциясе |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Зако-нына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы | Татарстан Респуб-ликасы Дәүләт Со-ветының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты<br><br>Закон проек-тының исемен түбәндәге редак-циядә бәян итәргә:<br>**«Казан шәһәрендәге районнар чикләрен үзгәртү турында һәм «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы За-конына үзгәрешләр кертү хакында»** | **«Казан шәһәрен-дәге районнар чикләрен үзгәртү турында һәм «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Зако-нына үзгәрешләр кертү хакында»** Татарстан Респуб-ликасы Законы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2. | | Казан шәһәрендәге районнар<br>чикләренең<br>карта-схемасы<br><br>«Казан шәһәрендәге<br>районнар чикләре турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>1 нче кушымта<br><br><br> | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты<br><br>Закон проектына кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:<br><br> |  |